Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Иске Роман авыл җирлеге Советы

Карары

2026 елның 16 феврале № 8\2

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Иске Роман авыл җирлеге Советының 05.06.2019 елның 63\1 номерлы «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Иске Роман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 28.12.2025 ел, №505-ФЗ Федераль закон нигезендә, Чистай шәһәр прокурорының 26.01.2026 ел, №020802-2026 Советның 05.06.2019 ел, № 63\1 карарына протестын карап, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Иске Роман авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Иске Роман авыл җирлеге Советының 05.06.2019 ел, № 63\1 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының» Иске Роман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәнең 13 маддәнең түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
3 пунктның 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«10) «коррупциягә каршы көрәш турында»2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр;
5 пунктта «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда» сүзләрен «гамәлдәге законнарда» сүзләренә алмаштырырга.
2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Иске Роман
авыл җирлеге башлыгы Р. Г. Дәүләтшина